# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлеге составына керүче Иске Лашчы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

20.11.2025 № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Килдураз авыл җирлегенең Иске Лашчы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; - ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү; - торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); өчен түләүгә Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2025 елның 20 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 184 катнашучы кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 95 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 93 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлегенең Иске Лашчы авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Килдураз авыл җирлегенең Килдураз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; - ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү; - торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); өчен түләүгә Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Иске Лашчы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Килдураз авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________ З.З. Әхәтов

Килдураз авыл җирлеге
башлыгы __________________ З.З. Әхәтов